**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 3 июлендәге 2841 номерлы карары

# 2024 елда «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында»гы, 2021 елның 3 ноябрендәге 2906 номерлы «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә карар бирәм:

1. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) 2024 елга норматив чыгымнарны әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның йогынтысы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
3 июлендәге 2841 номерлы
карары белән расланды

**«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) 2024 елга норматив чыгымнар**

| № т/б | Муниципаль эшнең (хезмәт күрсәтүнең) исеме | Муниципаль эшнең (хезмәт күрсәтүнең) эчтәлеге | Норматив чыгымнар (сум елга) |
|---|---|---|---|
| 1 | Территорияләрне планлаштыру буенча документлар әзерләү | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү | 31 974 628,26 |
| | | Территориянең чикләрен билгеләү проектын әзерләү | 5 992 140,74 |
| 2 | Җир кишәрлекләрен һәм күчемсез милек объектларын шәһәр төзелеше документларына туры килү-килмәвен тикшерү һәм өйрәнү | Җир кишәрлекләрен һәм күчемсез милек объектларын шәһәр төзелеше документларына туры килү-килмәвен тикшерү һәм өйрәнү | 4 833 370,00 |
| 3 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | 12 135 810,00 |
| 4 | Кадастр эшчәнлеген башкару | Дәүләт кадастр исәбен башкару өчен кирәкле мәгълүматларны эченә алган документларны әзерләү өлешендә күчемсез милеккә карата эшләр башкару | 5 186 573,10 |
| 5 | Эшчәнлекне административ яктан тәэмин итү | Проектлар белән идарә итү | 48 864 164,88 |
| | | Анализ ясау | 24 735 872,04 |
| | | Мониторинг үткәрү | 11 507 599,40 |
| 6 | Архитектура-төзелеш буенча проектлаштыруны башкару | Күчемсез милек объектларының проект-смета документларын эшләү | 48 090 941,58 |